КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 2 октябрь г.Казань № 895

2020 елда муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы укучыларны түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру чараларын гамәлгә ашыру өлешендә муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан мәгариф өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашуга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына субсидияләр бирү кагыйдәләрен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән 2020 елда муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы укучыларны түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру чараларын гамәлгә ашыру өлешендә муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан мәгариф өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашуга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына субсидияләр бирү кагыйдәләрен расларга.

2. Бу карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 2 октябрь, 895 нче
карары белән расланды

2020 елда муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы укучыларны түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру чараларын гамәлгә ашыру өлешендә муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан мәгариф өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашуга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына субсидияләр бирү кагыйдәләре

1. Әлеге Кагыйдәләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 22 февраль, 110 нчы карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасы кысаларында муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы укучыларны түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру чараларын гамәлгә ашыру өлешендә муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан мәгариф өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашуга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары (алга таба - муниципаль берәмлекләр) бюджетларына субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү тәртибен билгели билгели.

2. Әлеге Кагыйдәләр нигезендә бирелә торган бюджет акчаларын баш бүлүче - Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба - Министрлык).

3. Субсидияләр 2020 елга Министрлыкка әлеге Кагыйдәләрнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

4. Субсидияләр бирү өчен муниципаль берәмлекләрне сайлап алу критериесе - муниципаль берәмлек территориясендә башлангыч гомуми белем алучы укучыларны түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итү оештырылган муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының булуы.

5. Муниципаль берәмлекләр бюджетлары арасында субсидияләр бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

6. Субсидияләр бирү шартлары булып түбәндәгеләр тора:

муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан һәм башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укытуны гамәлгә ашыра торган муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе тарафыннан расланган норматив хокукый актларда билгеләнгән гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыруга карата санитар-гигиеник таләпләр һәм укучыларны тукландыруны

оештыруга карата башка таләпләр нигезендә кайнар аш белән тәэмин итүне оештыру өчен шартлар булу;

муниципаль берәмлек бюджетында (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет язмасында) финанслашу максатларында, аларны үтәү өчен кирәк булган күләмдә, Татарстан Республикасы бюджетыннан бирүгә планлаштырыла торган субсидия күләмен дә кертеп, субсидия бирелә торган муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен бюджет ассигнованиеләре булу;

муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы тарафыннан расланган муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы, әлеге белем бирү оешмаларында белем алучы укучылар санының 100 процентын тәэмин итүче укучыларның түләүсез кайнар туклануын оештыру чаралары исемлеге булу;

Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлек бюджетына субсидияләр бирү турында килешү (алга таба – Килешү) төзү, финанслау максатларында субсидияләр бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәү буенча муниципаль берәмлек йөкләмәсен һәм Килешүдә каралган йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җаваплылыкны күздә тота.

7. Субсидия Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 20 сентябрь, 851 нче карары белән расланган Җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләренең 10 пункты (алга таба – Субсидияләрне формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләре) нигезендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган типлаштырылган форма буенча Министрлык һәм муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы арасында төзелә торган килешү нигезендә бирелә.

8. I-муниципаль берәмлек бюджетына субсидияләр күләме ($S_i$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S_i = Ч_{бала\ көн_i} \times N_{пит} \times Z_{софинансирования},$$

монда:

$Ч_{бала\ көн_i}$ – әлеге Кагыйдәләрнең 9 пункты нигезендә исәпләнә торган i-муниципаль берәмлегендә башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алучы балалар саны;

$N_{тукл}$ – башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча бер укучыга бер көнгә кайнар ризыкның уртача бәясе 51,85 сум тәшкил итә;

$Z_{финанслашу}$ – Килешүдә билгеләнгән субсидияне куллануның нәтиҗәлелек күрсәткеченә (нәтиҗәсенә) ирешү зарурлыгыннан чыгып билгеләнгән һәм 27,85 процентка тигез кабул ителгән i-муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәсен Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслау дәрәҗәсе.

9. I-муниципаль берәмлектә ($Ч_{бала\ көн_i}$) башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алучы балалар саны түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Ч_{бала\ көн_i} = Ч_{бала\ көн\ 1\ кл_i} \times Дней_{1\ кл} + Ч_{бала\ көн\ 2-4\ кл_i} \times Дней_{2-4\ кл},$$

монда:

$Ч_{бала\ көн\ 1\ кл_i}$ – федераль статистик күзәтү мәгълүматлары буенча 2020 елның 1 гыйнварына i-муниципаль берәмлектә 1 нче сыйныфта укучылар саны;

$Дней_{1\ кл}$ – 1 нче сыйныф укучылары өчен уку көннәре саны 72 көнгә тигез;

$Ч_{бала\ көн\ 2-4\ кл_i}$ – федераль статистик күзәтү мәгълүматлары буенча 2020 елның 1 гыйнварына i-муниципаль берәмлектә 2 – 4 сыйныфларда белем алучылар саны;

$Дней_{2-4\ кл}$ – 2 – 4 сыйныфларда укучылар өчен уку көннәре саны 88 көнгә тигез.

10. Муниципаль берәмлек бюджетының субсидияләр исәбеннән финанслаша торган чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре күләме Килешүдә билгеләнгән субсидияне куллануның нәтиҗәлелек күрсәткеченә (нәтиҗәсенә) ирешү зарурлыгыннан чыгып, муниципаль берәмлек бюджеты турындагы карар белән раслана (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет язмасы белән билгеләнә).

11. Субсидияне куллануның нәтиҗәлелек күрсәткече (нәтиҗәсе) булып, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы укучыларны 100 процент түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итү тора.

12. Муниципаль берәмлекләр тарафыннан субсидияләрне файдалануның нәтиҗәлелеген бәяләү Министрлык тарафыннан Килешүдә билгеләнгән һәм субсидияне куллануның нәтиҗәлелек күрсәткеченең (нәтиҗәсенең) фактта ирешелгән күрсәткечен чагыштыру нигезендә башкарыла.

13. Муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып торган муниципаль берәмлекләр бюджетларының чыгымнары һәм субсидияләрдән файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткеченең (нәтиҗәсенең) әһәмияте турында Килешүдә каралган форма, сроклар һәм тәртип буенча Министрлыкка хисап тапшыра.

14. Муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары закон нигезендә тапшырыла торган хисап белешмәләренең дөрес булмавы һәм субсидияләрдән максатчан файдаланмау өчен җаваплы.

15. Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына субсидияләр Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә Федераль казначылыкның территориаль органнары тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары арасында керемнәрне исәпкә алу һәм аларны бүлү өчен ачылган счетларга гамәлгә ашырыла.

16. Килешүдә каралган йөкләмәләрне бозган очракта, муниципаль берәмлекләр бюджетларыннан субсидияләр акчаларын Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару тәртибе һәм шартлары субсидияләрне формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләренең 15 - 18, 23 пунктлары белән билгеләнгән.

17. Муниципаль берәмлек тарафыннан субсидияләр бирү шартларын бозган очракта аңа Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган бюджет мәҗбүриләү чаралары кулланыла.

18. Муниципаль берәмлек тарафыннан субсидияләр бирү шартларын үтәүне контрольдә тоту Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары тарафыннан башкарыла.

19. Субсидияне максатсыз куллану Татарстан Республикасы бюджетыннан закон белән билгеләнгән тәртиптә алынган акчалар суммасын бәхәссез түләттерүгә китерә.

20. 2021 елның 1 гыйнварына кулланылмаган субсидия чаралары 2021 елның беренче 15 эш көне дәвамында Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш.

Субсидиянең файдаланылмаган калдыгы Татарстан Республикасы бюджеты керемнә күчерелмәгән очракта, күрсәтелгән акчалар, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә, Татарстан Республикасы бюджеты керемнә алынырга тиеш.